БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№9.2016

Салават күпере





СЕНТЯБРЬ

«SK» КАЛЕНДАРЬ

ДҮШӘМБЕ	СИШӘМБЕ	ЧӘРШӘМБЕ	ПӘНҖЕШӘМБЕ	ҖОМГА	ШИМБӘ	ЯКШӘМБЕ
			1 Белем көне	2 Россия гвардиясе көне	3 Көзге урманга сәяхәт көне	4 Нефтьчеләр көне
5 Гладиолуслар көне	6 Гөмбә көне	7 Җирән чәчле кешеләр көне	8 Финансистлар көне	9 Дизайнерлар көне	10 Google туган көн	11 Уңыш җыю көне
12 Фотога төшү көне	13 Чәчтарашлар көне	14 Танкистлар көне	15 Кәрим Тинчуринның туган көне	16 Саркатипләр көне	17 Сок көне	18 Урман хезмәткәрләре көне
19 Смайлик туган көн	20 Халыкара ярканатлар көне	21 Халыкара тынычлык көне	22 Бөтендөнья автомобильсез йөрү көне	23 Сагыз туган көн	24 Көзге пейзаж ясау көне	25 Машина төзүчеләр көне
26 Диңгез көне	27 Тәрбиячеләр көне	28 Атом сәнәгате хезмәткәре көне	29 Туристлар көне	30 Россиядә интернет көне		

© «Салават күпере», 2016 ел.

Безнең VKontakte битенә «Салават күпере» журналы белән төшкән фотоңны куй һәм тавыш җый!

МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!



Айсылу, 6 яшь, Алексеевск.



Динә, 4 яшь, Казан.



Зөлфия, 7 яшь, Апас.



10 нчы «Алтынчәч» балалар бакчасы нәниләре, Азнакай.



Язилә, 1 яшь, Алексеевск.



291 нче балалар бакчасы сабыйлары, Казан.

«Ел тәрбиячесе» билгеле!

27 сентябрь – балаларга тәрбия бирүдә төп ярдәмчеләребез, якын дусларыбыз булган тәрбияче апаларның һөнәри бәйрәме. Шул уңайдан әле 2015 елның май санында ук «Ел тәрбиячесе» дигән бәйге игълан иткән идек. Аңа бер ел дәвамында бик күп эшләр кабул ителде. Тәрбияче апаларыбызның нинди өлгер, сәләтле, тырыш, үз эшләренең чын осталары икәнлегенә сокландык. Алга таба да сезгә уңышлар телибез!

Ә инде җиңүчеләргә килгәндә, алар www.salavatkupere.com сайтында барган тавыш бирү буенча өч номинациядә билгеләнде. Димәк, «Иң яхшы автор сценарие» язучы дип – Балтач районы Кариле балалар бакчасының рус теленә өйрәтүче тәрбиячесе Зөһрә Нургаян кызы РӘХИМҖАНОВА («Яңа ел тылсымы» эше), «Милли аспектлы иң яхшы дидактик уен» тәкъдим итүче булып – Казан шәһәренең Совет районы 50 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Рәсимә Рәшит кызы ГАЙНЕТДИНОВА («Балыкчы» эше), «Әти-әниләр белән уртак эшчәнлек» программасы авторы булып Казанның Совет районы 211 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Айгөл Марсель кызы САБИРОВА («Мәңге җуелмас хәтер» эше) табылды. Котлыйбыз!

Вәгъдә ителгәнчә, аларга бәйрәмнәре көнендә «Ел тәрбиячесе» дигән мактаулы исем белән беррәттән матур бүләкләр тапшырылачак.


Рәсимә Рәшит кызы ГАЙНЕТДИНОВА


Зөһрә Нургаян кызы РӘХИМҖАНОВА


Айгөл Марсель кызы САБИРОВА





Яраткан шагыйрәбез Сәҗидә апа Сөләйманова 1926 елның 3 октябрендә хәзерге Башкортстан Республикасы Яңавыл районы Яңавыл авылында туа.

1944 елда Тәтешле урта мәктәбен тәмамлагач, ул ике ел авылда укытучы булып эшли. С.Сөләйманова 1946–1950 елларда Уфада Башкорт педагогика институтының тарих-филология факультетында белем ала. Ә аннан соң Башкортстанның Әбҗәлил районында, Татарстанның Минзәлә шәһәрендә, соңрак Әлмәт нефть техникумында тарих укытучысы, КПССның Әлмәт шәһәр комитетында лектор һәм шәһәр радиоүзәгендә радиотапшырулар мөхәррире булып эшли. 1973 елдан Сәҗидә Сөләйманова язучылык эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Сәҗидә апа Сөләйманова – күп кенә шигырь җыентыклары, җыр текстлары, поэма, проза әсәрләре авторы. Аның балалар өчен язылган «Кем уяткан Ләйләне?», «Җиденче көз» китаплары безгә әйбәт таныш.

С.Сөләймbelieveнованың Мәскәүдә һәм Казанда русча тәрҗемәдә өч җыентыгы басылып чыга. Аерым шигырьләре украин, үзбәк, әзербәйҗан һ.б. милли телләргә дә тәрҗемә ителә.

Әдәбият һәм матбугат өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен 1980 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. 1963 елдан ул СССР Язучылар берлеге әгъзасы булып тора.

1980 елның 10 маенда Сәҗидә апа арабыздан китеп бара, әмма аның шигырьләре бүген дә яратылып укыла.

«АЛМА» ТҮГЕЛ, «АЛАМ»

Ал алмалар юа әни,
Тезеп куя өстәлгә.
– Аша, улым, алма, – диеп,
Берсен сузды Рөстәмгә.
Хата сизде Рөстәм сүздә:
– Аша алма, дисеңме?
«Аша» дигәч, «алма» димә,
«Алам» булсын исеме.




Сажида Сулейманова

НАХОДЧИВЫЙ РУСТАМ

Мама на кухне водой из-под крана
Яблоко моет для сына Рустама.
Спелое выбрала сыну сама:
– Кушай, сыночек мой! Это – алма.
Мальчик задумался: – Сьешь, говоришь.
Но, по-татарски «алма» –«не бери»?
Быстро ошибку исправил Рустам:
Пусть это яблоко будет «алам».*

* «алам» по-татарски означает «беру»

Перевод Талии ШАРАФИЕВОЙ






Sajida Suleymanova

«EAT YOURSELF», NOT «HELP YOURSELF»

Mother washed nice red apples,
She served them in a dish on the shelf.
– Here you are, son, help yourself,
She gave one of them to Rustem.
After her words Rustem chuckled:
– How can I help myself to an apple?
Or how can an apple help myself?
If it is an apple, I'll eat it myself!

Translation Dilyara Sharifullina


МӘКТӘП СУМКАСЫНА КИРӘКЛЕ ӘСБАПЛАРНЫ ТУТЫР.



КАЙСЫ ҖӘНЛЕК НИЧӘНЧЕ ВАГОНДА УТЫРА?



4-3





5-2

5-1





3-1

ТӨШЕП КАЛГАН СУЗЫК АВАЗЛАРНЫ ЯЗЫП, РӘТНЕ ДӘВАМ ИТ.


Кал...м

Д...фтәр

Чикләв...к

ГӨМБӘЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕН ЯЗЫП ЧЫК.












Җаваплар salavatkupere.com сайтында.



Айзилә КУНАФИЕВА,
Казан, 144 нче мәктәп,
11 яшь.



Айсылу ШӘЙДУЛЛИНА,
Мөслим, Исәнсеф-Чишмә,
9 яшь.



Диләрә АСЫЛОВА,
Казан, 167 нче мәктәп,
3 нче сыйныф.



Нурсил ЗАКИРОВ,
Арча, Яңа Кырлай мәктәбе,
2 нче сыйныф.



Варвара СЫРКИНА,
Казан, 62 нче мәктәп,
2 нче сыйныф.



Әминә МӘХМҮТОВА,
Казан, 116 нчы лицей,
3 нче сыйныф.



Раян ФӘТХЕЛИСЛАМОВ,
Азнакай,
6 яшь.



Айгөл БИКМОРАТОВА,
Казан,
13 яшь.



Алия АБЗАЛЕТДИНОВА,
Зәй,
4 яшь.

СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!

СКАЗКА О МАШЕ

Жила-была девочка по имени Маша. Она писала некрасиво, неаккуратно. Вот ручка на нее рассердилась и исчезла. Маша пошла в школу. И учитель ей сказал, что если она не сделает упражнение, то ей поставят плохую оценку. Она потянулась в портфель, но там ни тетради, ни ручки. Это все она попросила у одноклассницы. Маша написала очень аккуратно и ей поставили «5». Дома она села за домашнее задание и заглянула в портфель, там были и ручка, и тетради. И тут она поняла в чем секрет. Просто надо писать чисто и старательно.

Алина КАШАПОВА, Набережные Челны, СОШ №58, 4 класс.

КЕМ КӨЧЛЕРӘК?

Яшәгән ди, нәни генә Ут малае һәм Су кызы. Ут Судан бик көнләшкән һәм курыккан, шуның өчен аның зур буласы килгән.

– Судан көчлерәк булам, – дигән Ут һәм үсәргә җай эзли башлаган.

Көннәрдән бер көнне Ут малае очкын булып коры үлән арасына килеп төшкән һәм дөрли башлаган. Ул куанычыннан үрле-кырлы сикергән, зурайганнан-зурайган, куәтләнгән һәм тиз арада урманны, андагы агачларны, үләннәрне яндырып юкка да чыгарган.

Су кызы аларны бик кызганган һәм агачлар, үләннәр өстенә тылсымлы яңгыр булып явып киткән, урман өстенә салават күпере итеп матур буяулар элеп куйган. Агачлар, үләннәр яшәргәннәр, күз явын алырлык итеп яңадан чәчәк атканнар.

Ут малае җиңелгән, әмма бөтенләй юкка чыкмаган. Хәзер дә кемнең дә булса саксызлыгын көтеп кенә йөри, ди.

Раяз ШИҺАБЕТДИНОВ, Арча, 1 нче мәктәп, 5 нче сыйныф.

ӘТИ-ӘНИЕМ ҺӨНӘРЕ

Һөнәрләр бик күп төрле була. Җир йөзендә кырык меңнән артык һөнәр бар икән. Мин хәтта бу санны күз алдына да китерә алмыйм. Шулар арасыннан минем әтием Булат игенче һөнәрен сайлаган. Игенче хезмәте – хөрмәткә һәм ихтирамга лаек хезмәт. Әтием кояш белән бергә торып басуга китә. Яз көне иген чәчә, җәй буе аларны карап, тәрбияләп үстерә. Көз көне исә комбайны белән игеннәрне сугып, урып амбарларга озата. Аннан ул бөртекләр икмәк булып безнең табыннарга кайта.

Әнием Альфира авыл җирлеге башлыгының урынбасары булып эшли. Аның һөнәре – авыл халкының көнкүрешен кайгырту, аларга төрле яклап ярдәм күрсәтү, проблемаларын чишәргә булышу.

Мин әти-әнием белән чиксез горурланам.

Әлфис СӘХӘБЕТДИНОВ, Мөслим,
Вәрәшбаш мәктәбе, 2 нче сыйныф.

ДҮШӘМБЕ

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

СИШӘМБЕ

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________



ЧӘРШӘМБЕ

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

___сәг.___мин.______________________________

Дәр
Тәр

Сәл
Ку

ЯЗЫЛУ
П2339 (
73953

...слар
...мбе

...ат
...ре

...ДЕКСЫ:
...останда),
...сиядә)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

ҖОМГА

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

ШИМБӘ

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________

___сәг.___мин.___________________________



МУЗЫКА



Бигрәк матур жырлыйсың, Елмай! Әллә яңа жыр өйрәндеңме?





Рәхмәт, Шүркә. Мин җәйге каникулда музыка мәктәбенә йөрдем. Анда мине музыка дигән серле дөнья белән таныштырдылар.



Галимнәр музыканы борынгы кешеләр яшәгәндә үк барлыкка килгән дип исәпли. Ул аларның көндәлек тормышы белән бәйле булган: хатын-кызлар көйләп балаларын йоклаткан, көтүчеләр мөгездән ясалган быргыдан кычкыртып хайваннарны куган. Элекке заманнарда кешеләр табигать тавышларын кабатлаган, кул чабып яки тыпырдап ритм булдырган.
Музыка, мелодия, гармония, гамма кебек сүзләр грек теленнән кергән.




Кешеләр электән үк музыканы язып саклаган. Греклар моның өчен алфавит хәрефләрен кулланган. Ауропада махсус билге – невмалар булган. Алар сызык, нокта һәм өтер рәвешендә язылган. Россиядә ыргаклар кулланганнар. Болар ноталар барлыкка килүгә сәбәпче булганнар. Һәрбер илдә до, ре, ми, фа, соль, ля, си дигән ноталар билгеле.








Музыка коралларының исемнәрен яз.









Көй, музыка барлыкка килсен өчен уен кораллары кирәк. Элек музыка уен кораллары ролен таш, агач кисәкләре, кабырчыклар үтәгән. Африка кабиләләрендә бүген дә агачтан, кипкән кабактан ясалган барабаннар кулланалар. Бераз соңрак камилләшкән музыка кораллары барлыкка килгән. Шундый иң борынгы уен коралы дип флейта санала.

Музыка коралларының төрләре күп: кыллы (думбра, гитара, скрипка), тынлы (курай, флейта), бәрмә (барабан, ксилофон), телле (гармун, саксофон), клавишлы (фортепиано) һәм башкалар. Музыкантларның кыллы уен коралларында музыка әсәрләрен бергә башкаруы оркестр дип атала.


Ничек башкарылуга карап, музыка поп, рок, халык, классик, инструменталь, вокаль, хип-хоп, электрон музыка, блюз, джаз һәм башка төрле юнәлешләргә бүленә.

Музыкаль әсәрләр иҗат итүчеләрне композитор дип атыйлар. Классик музыка иҗат иткән Людвиг ван Бетховен, Иоганн Себастьян Бах, Вольфганг Амадей Моцарт, Пётр Ильич Чайковский, Джузеппе Верди кебек композиторлар бөтен дөньяга билгеле. Татарстан халкы Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, Резеда Әхиярова кебек мәшһүр композиторлар белән горурлана.

Ребусны чиш.

1 ОКТЯБРЬ – ХАЛЫКАРА . . . . . . КӨНЕ.







Ы



Көз бәйрәме

Сценарий

КАТНАШАЛАР:
ТӘРБИЯЧЕ АПА, БАЛАЛАР, ЯШЕЛЧӘЛӘР, КУЯН, КӨЗ КЫЗЫ, НАЧАР ҺАВА ТОРЫШЫ.

Зал көзге яфраклар белән бәйрәмчә бизәлгән. Матур көй астында балалар залга керә.

Тәрбияче: Хәерле көн, хөрмәтле әти-әниләр, кунаклар, балалар. Табигать буйлап алтын көз атлый. Без бүген көзнең матурлыклары, аның муллыклары турында шигырьләр сөйләрбез, җырлар җырларбыз. Безнең зал да әнә ничек матур итеп бизәлгән. Әйтерсең, алтын көз безнең залга кергән. Әйдәгез, көзге яфраклар турында җыр башкарып китик. *«Яфрак бәйрәме» җыры, Л. Лерон сүз., Р. Еникеев көе.*

Залда – кәрҗин. Кәрҗингә яшелчәләр тутырылган.

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле, кемдер яшелчәләр тулы кәрҗинен онытып калдырган. Кем безнең шундый уңган, булган икән? *Шулчак куян килеп чыга.*

Куян: Исәнмесез, балалар. Бу – минем кәрҗин. Мин бит кышка әзерләнәм. Җәй буе яшелчәләргә су сибеп үстердем. Инде менә уңыш җыеп алдым.

Тәрбияче: Куянкай-йомшаккай, ә нишләп соң син аларны бергә тутырдың?

Куян: Ашыктым. Миңа аларны аерырга булышыгыз әле.

«Яшелчәләрне аерабыз» уены.

Тәрбияче: Карагыз әле, яшелчәләр үзләре дә безгә килгән.

Чөгендер, кишер, кәбестә киемнәре кигән балалар керә.

Кәбестә:

Мин булам Кәбестә.
Үзем яшькелт төстә,
Күлмәгем күп катлы,
Үзем бик татлы.

Кишер:

Минем исемем Кишер.
Теләсәң, пешер,
Теләсәң, тура.
Мине яраткан бала
Озын гомерле була.

Чөгендер:

Мин чөгендер, чөгендер,
Синең сөйгән сыеңдыр.
Чия кебек төсләрем
Бизи өстәл өсләрен.

«Уңыш җыйдык» җыры,
Р.Асретдинова сүз., Н.Лотфуллина көе.



Тәрбияче: Рәхмәт сиңа, Куянкай. Рәхмәт сезгә, балалар. Карагыз, кем килә безгә? Көз кызы үзе килә. Рәхим ит, Көз кызы. *Кул чабып Көз кызын каршы алалар.*

Көз кызы: Исәнмесез, минем кадерлеләрем. Бүген сездә бәйрәм икәнен ишеттем дә килергә булдым. Сезнең белән уйныйсым, җырлыйсым, биисем килде.

Тәрбияче: Рәхмәт сиңа, Көз кызы. Син безгә муллык алып киләсең. Без сиңа рәхмәтлебез. Сине без ел да сагынып көтәбез. Син килүгә шигырьләр дә өйрәнеп куйдык.

1 бала:
Бик күңелле урамда –
Алтын-сары бар дөнья.
Җил яфраклар биетә,
Көз шатлана, туй итә.
«Кулчатыр» биюе.

2 бала:
Көзге муллык һәрвакытта
Булсын безнең табында.
Тату, дус яшик әле,
Матур булсын тагын да.
Көз кызы зал буйлап яфраклар очыра.

Көз кызы: Әйдәгез, бергәләп җырлап, биеп алабыз.
«Осень» җыры. И.Плакида сүз., И.Кишко көе.
Залга Начар һава торышы керә.

Начар һава торышы: Әпчи! Сез монда нишлисез?

Балалар: Көзге бәйрәм уздырабыз!

Начар һава торышы: Әпчи! Бәйрәм! Бу бик начар. Әпчи!

Тәрбияче: Гафу итегез, сез кем буласыз?

Начар һава торышы: Белмәгән булып кыланалар. Кем? Кем? Кем? – дип сораган булалар. Сезгә кем булса да ярамыймы әллә? Мин – бик начар һава торышы! Әпчи!

Тәрбияче: Бездә – бәйрәм. Шулаймы, балалар? Ә безгә мондый һава торышы кирәкми.

Начар һава торышы: Ничек кирәкми? Кирәк! Мин сезгә үземнең томаннарымны, салкын җилләремне, салкын көннәремне җибәрәм. Әпчи! Аннары сез авырыйсыз!

Көз кызы: Күрегез әле, ул безнең авыруыбызны тели.


Начар һава торышы: Әйе, шулай.

Көз кызы: Әйдәгез, балалар, бергәләп кул чабабыз, тыпырдыйбыз. Шулай итеп начар һаваны куабыз. *Балалар кул чаба, тыпырдый.*

Начар һава торышы: Ой-ой-ой! Сез нәрсә? Сез бик күп. Ә мин берүзем. Үзем китәм. Коткарыгыз! *Чыгып китә.*

Тәрбияче: Рәхмәт сиңа, Көз кызы. Син булганга гына без аны куып җибәрә алдык. Һәрвакыт янында якын дусларың булу кирәк. Әйдәгез, бергәләп «Дуслар» җырын җырлыйбыз. *«Дуслар» җыры. Р. Корбан сүз., Ф. Әбүбәкеров көе.*
Көз кызы балаларга көзге күчтәнәчләрен өләшә.

Галия Рафаэль кызы МИНҺАҖЕВА,
Теләче районының
3 нче номерлы
балалар бакчасы тәрбиячесе.



Барлас КАМАЛОВ

ИҢ КҮҢЕЛЛЕ КӨН

Хикәя

Бу көнне мин бик-бик көттем. Шуңа күрә дә мин бүген иртүк уяндым, иң беренче булып тордым. Гимнастика ясадым, яхшылап юындым, ашадым һәм киемнәремне кидем. Портфелемне тагын бер тапкыр ачып, әйберләремне карап алдым. Анда алты төрле карандаш, дәфтәрләр, кисмә хәрефләр, санау өчен таякчыклар, линейка һәм бетергеч – бар да бар. Ә «Әлифба» китабы хәзергә юк әле, аны бүген мәктәпкә баргач бирәчәкләр.

Мин ашыга-ашыга урамга чыктым. Мине әнием, әтием, дәү әтием белән дәү әнием, энем белән сеңлем озата чыктылар. Бар да миңа кул болгап калдылар.

Мәктәп ишеге төбендә безне укытучы апа каршы алды. Ул безне класска алып керде.

– Бүген беренче сентябрь. Сез беренче класска килдегез. Бүгеннән башлап сез инде укучылар булдыгыз. Бүген сезнең иң күңелле көнегез! – диде укытучы апа.

Мине укытучы апа Зөфәр исемле малай белән иң алгы партага утыртты. Укытучы апабыз Рәмзия Рәхимовна да шушы мәктәптә укыган икән. Беренче класста укыганда ул да шушы партада утырган. Менә кызык. Укытучы апа элек безнең кебек бәләкәй булган, беренче класста укыган.

Безнең мәктәптә бик күп, бик күп абыйлар, апалар укыган. Алар хәзер зур үсеп, төрле эшләр башкаралар: иген үстерәләр, терлек карыйлар, йортлар төзиләр, завод-фабрикаларда эшлиләр икән.

Мин дә тиздән зур үсәрмен. Үскәч кем булырмын – әлегә әйтә алмыйм. Тик шуны әйтә алам: мин тырышып укырмын.




ДУСКАЙ, Ә СИН БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФКА УКЫРГА БАРГАН КӨНЕҢНЕ ХӘТЕРЛИСЕҢМЕ? ШУЛ ТУРЫДА БЕЗГӘ КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ИНША ЯЗЫП ҖИБӘР. ИҢ ШӘП 5 ЯЗМА АВТОРЫН БҮЛӘКЛӘР – МӘКТӘП ӘСБАПЛАРЫ КӨТӘ!



Дуслар, менә тагын яңа уку елы башланды! Мәктәптә белем алучы барлык дусларыбызның тырышып укуларын, яңа уңышларга ирешүен телибез. Аларга белем дөньясында сәяхәт итәргә хөрмәтле укытучылары ярдәм итәр.
Ә 5 нче октябрьдә бу абый-апалар һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Әйдәгез, тәмле торт ясап, шатландырыйк әле үзләрен!



КИРӘКЛЕ ӘЙБЕРЛӘР: каймак (1000 г.), тозсыз балык печеньесы (500 г.), банан (3 шт.), шикәр комы (1 стакан), шоколад.





1 Каймакны шикәр комы белән кушып, яхшылап болгатабыз.

2 Аңа банан уабыз һәм барысын бергә кушабыз.






3 Торт савытына балык печеньесын салып, өстенә әзер массаны агызабыз.

4 Барысын бергә болгатып, тортны 4-5 сәгатькә суыткычка куябыз. Өстен шоколад белән бизибез.

SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORD



SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORD

АВЫЛ ХАТЫН-КЫЗЫ КИЕМЕ

Дусларым, әйдәгез әле бүген курчагыбызга авыл киемен әзерлик. Авыл киеме шәһәрнекеннән нәрсәсе белән аерыла дип уйлыйсыз? Авыл җирендә кешеләр гел хезмәт белән мәшгуль булганга, аларның киемнәре дә җиңелчә тегелгән. Мәсәлән, кызлар гади тукымадан тегелгән күлмәк кигәннәр. Күлмәкне пычранудан саклау өчен өстеннән алъяпкыч япканнар. Иң беренче алъяпкычлар күкрәкчәле булса, соңрак билгә бәйләп куела торганнарын гына тегә башлаганнар. Татар халкы гел чисталыкны яраткан. Шуңа да аш бүлмәсендә ризык әзерләгәндә алъяпкыч белән ак яулык бәйләү гадәти күренеш булган. Ә яшь кызлар алъяпкычны үзләре тегеп кенә калмаган, матур итеп чиккәннәр, бизәк тә төшергәннәр. Бертөрле төстәге ачык ситсы һәм сатин күлмәкләр өстеннән мондый алъяпкычлар бик матур күренгән. Печән һәм урак вакытында хатын-кызлар шулай ук кулларына җиңсәләр кигәннәр. Буйлап һәм ияк астына бәйләнгән, ә кыр эшләре вакытында баш артына бәйләп куелган ситсы яулык авыл хатын-кызының төп баш киеме булып киткән. Ә кыш көннәрендә ефәк шәл бәйрәм киеме булып саналган. Камзул да һәр хатын-кызның гардеробында булган. Аны туйдан соң кия башлаганнар. Авылда камзул урамда киеп йөрү өчен дә хезмәт иткән.

Авыл җирендә халык гел эштә булса да, хатын-кыз киемен бизәнү әйберләреннән башка күз алдына да китереп булмый. Йөзекләр, беләзекләр, акча тәңкәләреннән ясалган чулпылар һәм алкалар киемне тагын да баета торган була.

Руфия МӨХЕТДИНОВА, Татарстан Республикасы
Милли музееның матбугат үзәге җитәкчесе.







Фотолар «Татар милли киеме: тарих һәм хәзерге заман» күргәзмәсе каталогыннан алынды.

№9 (318) – 2016

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР (Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ (Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 22.09.16 ел.
Кәгазь форматы 60x90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-2198. Тираж: 8500 данә.

Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле.
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:
Татарстанда – П2339
Россиядә – 73953.

Тышлыкта – Азат (8 яшь) һәм Ралинә (3 яшь) Вакказовлар. Рәмис Нәҗмиев фотосы.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

МИЛЛИ КУРЧАК



Күлмәк

Яулык





Читек



Алъяпкыч



Читек

ISSN 0868-4545

